ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.07.2020 п.г.т.Алексеевское № 263

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районында
Татарстан Республикасы дәүләт телләре
турындагы законнарны гамәлгә ашыру
комиссиясе турында**

Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендә сәясәтне камилләштерү максатларында «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар теленнән файдалану турында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыруның алдагы чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 27 июнендәге 451 номерлы карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру комиссиясен төзергә һәм аның составын расларга (1-нче кушымта).
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру Нигезләмәсен расларга (2-нче кушымта).
3. «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Законны гамәлгә ашыру буенча район комиссиясе турында» 2015 елның 09 сентябрендәге 418 номерлы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 10 нчы июлендәге
263 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе:**

| | |
|---|---|
| Кадыйров Н.К. | - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе |

**Рәис урынбасары:**

| | |
|---|---|
| Симашева А.В. | - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

**Комиссия сәркатибе:**

| | |
|---|---|
| Скалова Л.И. | - Алексеевск район Советы юристы (килешү буенча) |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Йосыпова Г.Ә. | - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе |
| Кәлимуллин Т.Р. | - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Михайлова Л.В. | -Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы |
| Валеева З.Н. | - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты тәрҗемәчесе |
| Фасахов Р.А. | - «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының административ-техник инспекциясе» МКУ җитәкчесе |
| Монина И.Ю. | - Татарстан Республикасының «Татмедиа» АҖ филиалы «Заря» («Таң») җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Соловьев А.Г. | - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Свистунов И.К. | - Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Вилданов И.Х. | - «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Сафина Г.Т. | - «Эдем» ҖЧҖ директоры (килешү буенча) |
| Саттаров М.Д. | - «Алексеевскдорстрой» ААҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов Р.Б. | - «Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| _______________ | - Алексеевск муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре |

**Башкарма комитет эшләре идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 10 нчы июлендәге
263 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру Нигезләмәсе**

1. Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру комиссиясе Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында (алга таба - Комиссия) телләрнең үсешенә һәм гармонияле бәйләнешенә, милли-тел мөнәсәбәтләренең тотрыклы балансын саклап калуга юнәлдерелгән сәясәтне гамәлгә ашыру максатларында төзелгән һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты каршында даими эшләүче координация органы булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 25 октябрендәге 794 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын, «2014 - 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнары, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, учреждениеләр һәм уку йортлары, Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү өлкәсендәге сәясәткә кагылышлы башка норматив документларның (алга таба - телләр өлкәсендәге сәясәт) үзара хезмәттәшлеген һәм эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны үтәү буенча җирле үзидарә органнары, мәгариф һәм башка оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау, үз вәкаләтләре чикләрендә рекомендацияләр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

- Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары йөкләмәләрен үтәү.

4. Комиссия хокуклы:

- Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны үтәү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертергә;

- Комиссия эше өчен үз компетенциясенә кагылышлы кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук учреждениеләрдән, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан законнарда билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

- үз компетенциясе чикләрендә җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм кертергә;

- үз утырышларына чакырырга һәм җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, сәүдә объектлары вәкилләренең хисапларын тыңларга;

- үз вәкилләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, мәдәният һәм сәнгать оешмалары, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар, шул исәптән телләр өлкәсендә сәясәтне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан комиссия компетенциясенә кагылышлы актуаль мәсьәләләр буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен җибәрергә;

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә җәмгыять тормышының барлык өлкәләрендә Татарстан Республикасы дәүләт телләренең тигез хокуклы һәм оптималь эшләвен, аларның үзара хезмәттәшлеген һәм алга таба үсешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар инициаторы булырга.

5. Комиссия түбәндәгеләргә бурычлы:

- Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында Татарстан Республикасы законнарын билгеләнгән вакытларга кергән саен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары йөкләмәләрен үтәргә;

- Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә һәркем өчен мөмкин булган мәгълүматны урнаштыруны тәэмин итү чараларын күрергә;

- гражданнар һәм оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәүне тәэмин итү чараларын күрергә;

- район җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә үз составына керә торган Алексеевск районы һәм җирлекләр территориясендә Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законнары таләпләрен үтәүнең торышы турында мәгълүмат бирергә.

6. Комиссия Комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм Комиссия әгъзалары составында төзелә, алар аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнашалар. Комиссия составы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

7. Комиссия рәисе - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе.

8. Комиссия утырышлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләр йомгаклары буенча айга кимендә бер тапкыр уздырыла.

9. Комиссия утырышларын уздыруны көн тәртибенә әзерләү һәм оештыру, шулай ук Комиссия эшчәнлегенең агымдагы мәсьәләләрен хәл итүне Комиссия рәисе урынбасары, комиссия сәркатибе белән берлектә, нәтиҗәләрне исәпкә алып гамәлгә ашыралар.

Комиссия утырышын көн тәртибе, үткәрү датасы һәм тәртибе Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә. Кирәк була калса, комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырыла ала.

Комиссия әгъзалары утырышның аны үткәрү көненә кадәр 3 көн кала комиссия сәркатибе тарафыннан хәбәр ителә.

10. Комиссия үз эшчәнлеген аның утырышларында кабул ителә торган һәм Комиссия рәисе тарафыннан раслана торган эш планнары нигезендә гамәлгә ашыра.

11. Комиссия утырышын Комиссия рәисе йә аның йөкләмәсе буенча Комиссия рәисе урынбасары үткәрә.

12. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия утырышында шәхси катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендәге учреждениеләр һәм оешмалар мәнфәгатьләрен тәкъдим итүче комиссия әгъзалары үз оешмаларының башка вәкилен җибәрә.

13. Комиссия карарлары комиссиянең утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

14. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана. Комиссия карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләр беркетмәләрен үтәү йөкләмәләреннән тыш, рекомендация характерында була.

Комиссия әгъзалары өчен Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрнең беркетмәләрен үтәү бурычы мәҗбүри характерда.

15. Комиссия карарларының үтәлешен комиссиянең сәркатибе контрольдә тота.

**Башкарма комитет**
**эшләре идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**